Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XLV-8**

Балык Бистәсе штп. 2019 елның 24 сентябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2009 елның 27 июлендәге XXXX-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органында муниципаль хезмәткәрнең шәхси мәгълүматлары белән эшләүне оештыру һәм аның личное делосын алып бару турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга тәңгәлләштерү максатларында, 2019 елның 1 апрелендәге "“Мәҗбүри пенсия иминиятләве системасында индивидуаль (персонификациялөнгән) исәп турында” Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” 48-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының 2014 елның 1 июлендәге “Россия Федерациясе Президентының кайбер актларын үзгәртү һәм көчен югалтуын тану турында” 483 номерлы, 2019 елның 23 июлендәге “2005 елның 30 маенда Россия Федерациясе Президентының 609 номерлы Указы белән расланган Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәткәренең шәхси мәгълүматлары һәм аның личное делосын алып бару турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында” 353 номерлы Указлары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2009 елның 27 июлендәге XXXX-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органында муниципаль хезмәткәрнең шәхси мәгълүматлары белән эшләүне оештыру һәм аның личное делосын алып бару турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 7.3. пунктының 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“е) белеме һәм квалификациясе турындагы документларның, өстәмә һөнәри белем алу нәтиҗәләре буенча квалификация күтәрү яки бирелүне раслаучы, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирелү (андыйлар булган очракта) турындагы документларның күчермәләре;”.

1.2. 7.3 пунктының 23 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“23) индивидуаль (персонификацияләнгән) исәп системасында теркәлүне раслаучы документ күчермәсе;”.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының законлылык, хокук саклау, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Таҗетдинов